КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 июль г.Казань № 515

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын түбәндәгеләр буенча вәкаләтле республика башкарма хакимият органы итеп билгеләргә:

муниципаль учреждениеләрдә, расланган һөнәри квалификация төркемнәреннән һәм эшчеләр һөнәрләрен һәм хезмәткәрләр вазыйфаларын һөнәри төркемнәргә кертү критерийларыннан файдаланып, Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеге («Мәдәният,

сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» һәм «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» бүлекләре), шулай ук һөнәри стандартлар реестры (һөнәри эшчәнлек төрләре исемлеге) нигезендә төзелгән мәдәният хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлеген раслау буенча;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү турында карар кабул итү буенча.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән һәм чикләрендә, шул исәптән федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына чираттагы финанс елына әлеге максатлар өчен каралган субсидияләр исәбеннән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

5. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 июль, 515 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 317 номерлы карары белән расланган «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының 37 нче кушымтасында бирелгән Россия Федерациясенең халкы 50 мең кешегә кадәр булган торак пунктларына килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен (алга таба шул ук эзлеклелектә – мәдәният хезмәткәрләре, бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве түбәндәге мәдәният хезмәткәрләренә бирелә:

югары белемле яисә урта һөнәри белемле Россия Федерациясе гражданнары булган;

агымдагы елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы карамагындагы мәдәният оешмасы (алга таба шул ук эзлеклелектә – муниципаль берәмлек, мәдәният оешмасы) белән Россия Федерациясенең хезмәт законнары нигезендә билгеләнгән тулы эш көне һәм, расланган һөнәри квалификация төркемнәреннән һәм эшчеләр һөнәрләрен һәм хезмәткәрләр вазыйфаларын һөнәри төркемнәргә кертү критерийларыннан файдаланып, Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеге («Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» һәм «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» бүлекләре), шулай ук һөнәри стандартлар реестры (һөнәри эшчәнлек төрләре исемлеге) нигезендә төзелгән, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан расланган мәдәният хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфада хезмәт функцияләрен башкару шартларында хезмәт шартнамәсен (алга таба шул ук эзлеклелектә – вакантлы вазыйфалар исемлеге, хезмәт шартнамәсе) төзегән;

Министрлык һәм муниципаль берәмлек белән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзегән.

Әлеге Тәртиптә мәдәният оешмалары дигәндә мәдәният оешмалары, шулай ук «балалар сынлы сәнгать мәктәбе», «балалар музыка мәктәбе», «балалар хор мәктәбе», «балалар сәнгать мәктәбе», «балалар хореография мәктәбе», «балалар театр мәктәбе», «балалар цирк мәктәбе», «балалар сәнгать һөнәрләре мәктәбе» дигән махсус атамалы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә һөнәри белем бирү оешмалары, шул исәптән аларның гамәлгә куючылары Министрлык яисә муниципаль берәмлек булган структур һәм аерымланган бүлекчәләре аңлашыла.

3. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен алучылар саны тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләменнән һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан чыгып билгеләнә. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве 1 млн.сум күләмендә бер тапкыр түләнә.

4. Мәдәният хезмәткәре Министрлыкка, агымдагы елның 10 сентябреннән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документларны тапшыра.

Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алу өчен гариза формасы Министрлык боерыгы белән раслана.

5. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

мәдәният хезмәткәре шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

һөнәри белем турында һәм (яисә) квалификация турында документ (өстәмә бите белән) күчермәсе;

мәдәният оешмасы тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) электрон хезмәт кенәгәсеннән хезмәт эшчәнлеге турында белешмә (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырылган очрактан тыш);

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) үзгәргән очракта – фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда) үзгәртү турындагы документ күчермәсе;

бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен күчерү өчен кредит оешмасында ачылган счетның реквизитлары белән кредит оешмасыннан белешмә;

мәдәният оешмасы тарафыннан расланган хезмәт шартнамәсе күчермәсе.

Документларның таныкланмаган күчермәләре мәдәният хезмәткәре тарафыннан, тәңгәл булуын чагыштырып карау өчен аларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, бер үк вакытта тапшырыла, шуннан соң документларның төп нөсхәләре шунда ук мәдәният хезмәткәренә кире кайтарыла.

Мәдәният хезмәткәре үзе тапшырган документларда (документлар күчермәләрендә) күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен җавап бирә.

Мәдәният хезмәткәреннән кергән гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көнне Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә.

6. Министрлык әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм

документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә:

тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны керү чираты тәртибендә карап тикшерә;

Министрлык боерыгы белән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен бирү турында яисә әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган нигезләр буенча аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

тиешле карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә мәдәният хезмәткәренә аңа бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында, шулай ук шартнамә төзү датасы, вакыты һәм урыны турында яисә аны бирүдән баш тарту турында язма рәвештә хәбәр итә.

Министрлык тарафыннан бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карарлар кабул итү әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар керү чираты тәртибендә гамәлгә ашырыла.

7. Министрлык мәдәният хезмәткәренә түбәндәге очракларда бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен бирүдән баш тарта:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган документлар тапшырылмау яки тулы күләмдә тапшырылмау;

әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган гариза белән мөрәҗәгать итү срогы бозылу;

тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр ачыклану;

мәдәният хезмәткәре әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү.

8. Министрлык бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә шартнамәнең өч нөсхәсенә кул куя һәм муниципаль берәмлек исеменнән эш итәргә хокуклы зат һәм мәдәният хезмәткәре кул кую өчен аларны муниципаль берәмлеккә җибәрә.

Муниципаль берәмлек шартнамәнең өч нөсхәсен алган көннән алып 10 эш көне эчендә аңа мәдәният хезмәткәре һәм муниципаль берәмлек исеменнән эш итәргә хокуклы зат тарафыннан кул куюны тәэмин итә.

Шартнамәгә кул куелганнан соң муниципаль берәмлек бер нөсхәсен мәдәният хезмәткәренә, бер нөсхәсен кул куелганннан соң өч эш көне эчендә Министрлыкка кире кайтара.

9. Шартнамә формасы Министрлык боерыгы белән раслана һәм анда мәдәният хезмәткәре өчен түбәндәге йөкләмәләр карала:

хезмәт шартнамәсе төзелгән көннән алып биш ел эчендә хезмәт вазыйфаларын хезмәт шартнамәсе нигезендә вазыйфа буенча, шул исәптән хезмәт функцияләрен үтәмәгән чор өчен хезмәт шартнамәсен озайту шартларында тулы күләмдә башкарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 107 статьясында каралган ял вакытыннан башка, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 255 – 257 статьяларында каралган очраклардан тыш);

әлеге пунктның икенче абзацында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, хезмәт шартнамәсен өзгәндә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 8 пунктында

һәм 83 статьясындагы беренче өлешенең 5 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсен өзү очракларыннан тыш);

әлеге пунктның икенче абзацында каралган йөкләмәләрне өлешчә үтәмәгән очракта, шулай ук мәдәният хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлегенә кермәгән башка вазыйфага күчерелгән яисә өстәмә һөнәри программалар буенча укырга кергән очракта, хезмәт шартнамәсе өзелгән көннән алып биш ел срок тәмамланганга кадәр эшләнмәгән чорга пропорциональ исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 8 пунктында һәм 83 статьясындагы беренче өлешенең 5 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсен өзү очракларыннан тыш);

хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта, хезмәт шартнамәсе өзелгән көннән алып эшләнмәгән чорга пропорциональ исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 83 статьясындагы беренче өлешенең 1 пункты нигезендә) яисә функциональ вазыйфалар үтәлмәгән чор өчен хезмәт шартнамәсенең гамәлдә булу срогын озайтырга (хезмәткәрнең сайлавы буенча).

10. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве мәдәният хезмәткәренә муниципаль берәмлек тарафыннан, агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча, Россия кредит оешмаларында ачылган мәдәният хезмәткәрләре счетларына акча күчерү юлы белән башкарыла.

11. Мәдәният оешмасы мәдәният хезмәткәре белән хезмәт шартнамәсе өзелгән көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкка аны эштән азат итү турындагы боерык күчермәсен җибәрә.

12. Министрлык, мәдәният хезмәткәрен эштән азат итү турында боерык күчермәсен алган көннән алып 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, мәдәният хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен (бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең бер өлешен) кире кайтару турында таләп җибәрә.

13. Мәдәният хезмәткәре бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен (бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең бер өлешен) кире кайтару турындагы таләпне ул алынган көннән алып 30 календарь көн эчендә үтәргә тиеш.

Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве (бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең бер өлеше) әлеге пунктта күрсәтелгән срок эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, Министрлык кире кайтарылырга тиешле бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен (бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең бер өлешен) суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә.

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 14 июль, 515 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – мәдәният хезмәткәре, бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре, муниципаль берәмлек, башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар мәдәният хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

Министрлык һәм муниципаль берәмлек арасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү;

муниципаль берәмлектә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен алучылар булу.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре түләнгән мәдәният хезмәткәрләре саны.

7. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлек Министрлыкка, башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗның финанс-икътисадый нигезләвен теркәп, башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле формада заявка (алга таба – заявка) тапшыра.

Заявка Министрлыкта кергән көнендә теркәлә.

8. Министрлык:

гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә гаризаны карап тикшерә;

заявка теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә башка бюджетара трансферт бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә муниципаль берәмлеккә башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында язма хәбәр бирә.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү;

әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

11. i-муниципаль берәмлек ($C_i$) бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = (N_i \times 1\ 000\ 000),$$

монда:

$N_i$ – i-муниципаль берәмлек территориясендәге бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен алучылар саны;

1 000 000 – бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве күләме.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

13. Муниципаль берәмлек хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр Министрлыкка Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча түбәндәгеләрне тапшыра:

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап.

14. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән башка

бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткечен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

15. Муниципаль берәмлек әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә бирелә торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

16. Хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансферт елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

17. Әгәр хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына карата муниципаль берәмлек тарафыннан Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган булса, башка бюджетара трансферт хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары муниципаль берәмлеккә карата әлеге Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яисә) муниципаль берәмлек тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___